# REVIEW OF THE D.B.RAMAZANOVA'S MONOGRAPH *VOCABULARY RELATED TO HUMAN BEINGS.* KAZAN, IYALI PUBL., 2013. 364 P.

**Raushaniya Sagdatzyanovna Nurmukhametova,**
Kazan Federal University,
2 Tatarstan Str., Kazan, 420021, Russia,
rsagadat@yandex.ru

The article reviews the monograph "Vocabulary Related to Human Beings" by D.B.Ramazanova, Doctor of Philology, Professor. In this book by the famous dialectologist, Tatar lexical and semantic group is singled out for research (LSG describing parts of the body as well as human emotions, clothes, make-up, measure of weight, etc) and is analyzed in diachronic and synchronic aspects and in comparison with other languages. The paper describes semantic transitions in proper names, genetic aspects of vocabulary, and presents examples of vocabulary shared by Tatar with the Finno-Ugric languages. The fact that this group of words was formed in remote times is substantiated by extensive factual material.

**Key words**: vocabulary, lexical and semantic group, somatisms, terms.

From ancient times to the present, people have been unable to study language in its every detail. Numerous theories and works are devoted to this issue at each stage of linguistic evaluation. Generation after generation of researchers have made great efforts to discover unknown features of language, thus new trends have developed in various fields of linguistic studies.

Currently, linguistic research studies language not only as a means of communication or learning, but as the cultural code of nations. New methods of research and changes in global social and cultural processes are some reasons for the development of new linguistic and cultural studies which deal with the relationship between language and culture.

Many researchers think language should be studied in connection with national culture and mentality, as this approach reveals each person's psychological outlook and peculiarities of thinking. Linguistic and cultural studies based on the material from the Tatar language have been the subject matter for researchers from Kazan Federal University, mainly. For 20 years, R.R.Zamaletdinov, Doctor of Philology and Professor, has been the head of the scientific school for cultural linguistics.

Many aspects of Tatar linguistic and cultural studies need clarification and assessment. We know, however, what methods to employ to accomplish the task and promote the efficiency of future research. Thus, studying a language's lexicon and analysing the words, which remain primarily only in dialects have become topical in the last few years. Discovering features of vocabulary found in local people's speech and studying dialect vocabulary results in great contributions to linguistic and cultural studies.

Multifaceted studies of dialect vocabulary are of great importance both for linguistics and for national history. Researchers use different methods to study the vocabulary of languages in detail. One such recently published work is the monograph "Vocabulary Related to Being Human". The author of the work, D.B.Ramazanova, Professor and Doctor of Philology, a researcher in the G.Ibragimov Institute of Language, Literature and Art, Honorary Culture Worker for the Republic Tatarstan, Honorary Scientific Worker of the Republic Tatarstan, is known among linguists for the depth of her scientific research. Having studied Tatar dialects for over half a century, D.B.Ramazanova is the author of 24 books and dictionaries (including 9 monographs) and more than 450 papers on Tatar dialectology, history, lexicology and lexicography, onomastics, terminology, and material and spiritual culture.

"Vocabulary Related to Human Beings" is based on material collected by this famous researcher during expeditions to different places in Tatarstan and Russia where the Tatars live. The book under review analyzes vocabulary related to human beings.

Historically, this vocabulary developed in the remote past. The lexical and semantic group of words, related to the parts of the body, states of mind and character is the largest and the most unalterable group in Tatar. This fact is substantiated by research in the field of anthropocentrism, a recently developed trend in modern linguistics.

D.B.Ramazanova's work consists of five chapters. The first and second chapters are devoted to vocabulary describing the structure of the body: body parts, and changes in terms' meaning as well

as characteristics of these parts of the body. Common features of different human body parts are described here. The author mentions that these words are the oldest layer of vocabulary and therefore common for many Turkic languages, characterized by the same features as other terms (concrete definition, instantiation, etc.).

Exploring these units, the researcher demonstrates the methods used (semantic transition, nomination, metaphor, comparison) for inclusion of these somatisms in other lexical and semantic groups (clothes, make-up, measure of weight, names of lands and bodies of water, flora and fauna, onomastics, etc.). For example, in evaluation of the word *"baash"* ('head') each method is employed in turn, substantiated by tables given in the book. The polysemy of somatisms proves their ancient origin and the extensive factual material in D.B.Ramazanova's book testifies to this fact. The book further demonstrates that language is a social phenomenon, which allows for evaluation. In the course of social development, when people need terms for new concepts, they may use association or metaphor to solve the problem:

1) *күз* (an eye) → *буш тишек, чокыр* (an empty hole) → *икмәктәге күзләр* (eyes in bread) → *шәл бәйләгәндәге тишекләр* (holes appearing in knitting a shawl) → *ачкыч тишеге* (key hole) → *тегермән ташы тишеге* (a hole or an aperture in a millstone) etc.;

2*) күз* (an eye) – *кайнап чыга торган чишмәнең тулып торган чокыры* (the place where the spring gushes out and the water is accumulated)→ *күлләвекнең уртасы* (a center of lowland) → *җылу* (an ice-hole) → *мөлдерәмә тулы чиләк* (a pailful) etc. → *боткада май чокыры* (a pit in the porridge for butter) etc.

The author is right to suggest polysemy as impetus from the remote past.

The third chapter of the monograph explores words, which denote a human's character, inner life, and psychological state. This group of words differs from other groups from Tatar in meaning, origin, and word-formative features.

The words for evaluating human beings are characterized by their generalized meaning, i.e., they lack specific features. For example, the word *"чибәр"* (beautiful) is a synonym of the word *"матур"* (pretty). This term has other meanings in the various dialects, however: *яхшы* ('good'), *әйбәт* ('fine'), *шәп* ('cool'), *тәртипле* ('well-mannered'), *сак, иплән (йөрү)* ('(walk) gingerly'). The meanings of a number of words from this group tend to change: *кыланчыклану* (making faces) → *мактану, кылану* (boasting) – *эреләнү* (becoming larger or self-important), etc.

In Tatar dialects, one large semantic group includes words like *"җукы", "тәкәббер", "тәпәренү"* (arrogant). The author shows all their morphological variants and explains them by revealing the inner, semantic and grammatical capabilities of the Tatar language.

Words which denote a human's character and inner world have common features in origin and form. Most words of this group are derivatives, formed by adding productive suffixes: *зиһенле* (intelligent), *ямьсез* (ugly), *акыллы* (clever), *чәүчәләк* (anxious), *күркәм* (attractive); *баштак* (arbitrary), *портак* (careless); *кукыр* (boastful), *ацланҗыр* (angry), *сизгер* (sensitive); *борнай* (whimsical), *сатай* (crazy) etc.. Or, these may be words defining persons, related to outstanding people and social terms: *каун* (melon), *йот* (glutton), *әзмәвер* (a big fellow), etc.

The fourth chapter deals with Tatar medical vocabulary and names of diseases. The material was not the object of research in terms of cultural linguistics or any other aspect previously. Names of diseases, different ways in which we heal, are related to a nation's spiritual life, faith, and aesthetic views – all of which reveals human philosophical thought. All these phenomena play an important role in creating the global image described in language. This chapter is of great value for us as it provides extensive material for further research in the field of cultural linguistics.

The fifth chapter, titled "Derivative Endings Related to Being Human", deals with derivative endings of words, examples in the book under review. Chapter material proves that the vocabulary related to being human is indeed of ancient origin: most derivative endings were active ones (they can be found in a large number of words), however, at present, many of them have become unanalyzable, it is difficult to distinguish them as morphemes. For example, *'-әби: чәтнәби, чәтәби, әтәмби; -мыр/-мер: бетмер, кысмыр, пытымыр, чыкмыр'*, etc. We should emphasize that these endings are infrequent, however. In dialects they are distinguished as word-formative. The fact is based on extensive factual material.

One of the novel findings in D.B.Ramazanova's book is in the semantic aspect of the research. In general, semasiology is the focus of current linguistic studies. This monograph can be assessed as scientific research, which satisfies the requirements of our time and reflects relevant issues of modern linguistics. It focuses on the

transition of meaning and the scope of stem meanings and their development.

Among meaning transitions, which is a characteristic feature of somatisms, the transition of a name from a body part to a piece of clothing, covering this part of the body, is an active one. The book reveals in a systematic way the transition *part of the body* to *a piece of clothing*. This pattern allows for reconstruction of names lost over time.

To conclude, we should note – this work proves that many words related to the nature of being human and of human beings in the Tatar literary language and its numerous dialects are genetically complicated and varied in structure. The extensive factual material of the book reveals that these words occupy a primary place in Tatar vocabulary and play a key role in its formation. D.B.Ramazanova's monograph "Vocabulary Related to Human Beings" makes a great contribution to the study of relevant issues in Tatar linguistics. The data collected by the author has been verified and thoroughly analyzed. We think this book will open up a novel avenue for the study of other thematic groups. The Lexical studies allow us to learn more about our nation's past, our culture, and changes the language has undergone in the course of its development.

---

# Д.Б.РАМАЗАНОВАНЫҢ «ТАТАР ТЕЛЕНДӘ КЕШЕГӘ БӘЙЛӘНЕШЛЕ ЛЕКСИКА» (КАЗАН: ИЯЛИ НӘШР., 2013. – 364 Б.) МОНОГРАФИЯСЕНӘ БӘЯЛӘМӘ

**Раушания Сәгадәтҗан кызы Нурмөхәммәтова**,
Казан федераль университеты,
Россия, 420021, Казан, Татарстан ур., 2,
rsagadat@yandex.ru

Бәяләмә филология фәннәре докторы, профессор Д.Б.Рамазанованың «Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика» монографиясенә багышлана. Танылган диалектологның әлеге китабында сайлап алынган лексик-семантик төркем диахроник һәм синхроник аспектта, башка телләр белән чагыштырып өйрәнелә; кешегә бәйле кайбер атамалардагы мәгънә күчешләре тасвирлана; бу сүзләрнең генетик катламнары ачыклана; фин-угыр телләре белән уртак лексикадан кызыклы мисаллар китерелә. Хезмәттә кешегә бәйле сүзләр төркеменең телдә борынгыдан формалашкан булуы бай фактик материал нигезендә дәлилләнә.

**Төп төшенчәләр:** лексика, лексик-сематик төркем, соматизмнар, терминнар.

Борынгы чорлардан алып бүгенге көнгә кадәр кешелекнең телне һәм аның асылын ахырына хәтле ачып бетерә алганы юк. Тел белеме фәненең һәр үсеш этабында бу проблемага багышланган үзенчәлекле теорияләр, хезмәтләр дөнья күргән. Алардан соң килгән буыннар да телнең моңарчы билгеле булмаган үзенчәлекләрен ачуга зур өлеш керткән, шул рәвешле телдә яңа юнәлешләр барлыкка килгән.

Бүгенге көн тел белеме фәнендә эшчәнлек XX гасыр ахырында кабул ителгән үсеш юнәлеше кысаларында алып барыла. Тел аралашу, танып белү чарасы итеп кенә түгел, ә милләтнең мәдәни коды буларак та өйрәнелә башлады.

Шул юнәлештә фәнни эзләнүләр барлыкка килү, дөнья күләмендә социомәдәни процессларның үсү-үзгәрүе, фәндә тел һәм мәдәният мөнәсәбәтләрен өйрәнә торган махсус тармак – лингвокультурология оешуга этәргеч бирде. Әлеге фән тамырлары белән гуманитар фәннәрнең мәдәният һәм тел чигендә тора, турыдан-туры аларның үзара бәйләнешен өйрәнә.

Телне, бигрәк тә аның сүзлек байлыгын халыкның мәдәнияте, аның фикерләве, фикер йөртү үзенчәлекләре белән бәйләнештә алып барганда кешенең фәлсәфи карашларын, уй йөртү үзенчәлекләрен тирәнрәк аңлап булуы бүген күп кенә телче галимнәр тарафыннан кабул ителә. Татар теле материаллары нигезендә лингвокультурологик тикшеренүләрне, нигездә, Казан федераль университеты базасында эшләүче галимнәр алып бара. Ике дистә ел эчендә филология фәннәре докторы, профессор

Р.Р.Җамалетдинов җитәкчелегендә фәнни мәктәп тә оешты.

Татар лингвокультурологиясе өлкәсендә тикшерәсе һәм ачыклыйсы мәсьәләләр бихисап, шул ук вакытта бүген әлеге эшләрне башкару ысуллары һәм юнәлешләренең чикләре инде якынча билгеләнгән булуы алдагы тикшеренүләр өчен уңай җирлек тудыра. Бу нисбәттән соңгы елларда телләрнең сүзлек фондын өйрәнү мәсьәләләренә игътибар арту сөйләшләрдә генә сакланып килгән сүзләрне төрле яссылыкта тикшерүне дә актуальләштерә. Җирле төбәкләрдәге үзенчәлекләрне барлау һәм диалекталь лексиканы өйрәнү дә тел – мәдәният багланышларын ачыклауга зур өлеш кертә, лингвокультурологик эзләнүләр өчен бай материал бирә.

Диалектларның лексикасын төрле яклап өйрәнү тел белеме фәне өчен генә түгел, халык тарихы өчен дә әһәмиятле нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Телнең сүзлек фондын тулаем, комплекслы итеп тикшерүгә омтылу галимнәрне төрле алымнар белән тикшеренүләргә этәрә, лексик фондны төрле яклап барлау юллары ачыла. Әле күптән түгел генә дөнья күргән «Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика» дип аталган шактый зур күләмле монография – нәкъ менә шундый тикшеренүләрнең берсе. Хезмәтнең авторы Д.Б.Рамазанова тел белгечләре арасында үзенең тирән эчтәлекле, үзенчәлекле фәнни хезмәтләре белән яхшы таныш. Ул – филология фәннәре докторы, профессор, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фәнни хезмәткәре, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе. Д.Б.Рамазанова ярты гасыр дәвамында татар теленең диалектларын өйрәнә, ул егерме дүрт китап (шул исәптән тугыз монография) һәм сүзлек авторы, аның татар теленең диалектологиясе, тарихы, лексикология һәм лексикография, ономастика, терминология, татар халкының матди һәм рухи мәдәнияте турында 450 дән артык фәнни мәкаләсе дөнья күргән.

«Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика» хезмәте танылган галимәнең Татарстан Республикасы һәм Россиянең татарлар яшәгән өлкәләренә үткәргән экспедицияләрдә тупланган материаллары нигезендә язылган. Бу китапта кеше белән бәйле лексика төрле яссылыкларда тикшерелә.

Билгеле булганча, әлеге лексика, тарихи күзлектән караганда, бик борынгы чорларда формалашкан. Татар телендә кешенең әгъза атамаларын, рухи халәтен, холкын белдерә торган сүзләрдән торган лексик-семантик төркем күләме белән дә, тотрыклылыгы ягыннан да беренче урында тора. Хәзерге тел белемендә зур үсеш алган антропоцентризм юнәлештә башкарылган хезмәтләр моның шулай булуын һәрдаим дәлилләп тора.

Д.Б.Рамазанованың хезмәте биш бүлектән тора. Беренче һәм икенче бүлекләр кешенең тән төзелеше белән бәйле берәмлекләрне тикшерүне күздә тота: кеше әгъзалары атамалары һәм аларда мәгънә күчешләре, шул әгъзаларның сыйфатлары белән бәйле сүзләр барлана. Әлеге бүлекләрдә кеше әгъзаларының гомуми үзлекләре сыйфатлана. Автор аларның сүзлек составында иң борынгы катлам булуына һәм шуңа күрә күпчелек төрки телләр өчен уртак икәнлегенә басым ясый, әгъза атамаларында терминлыкка хас сыйфатлар (конкретлык, төгәл эчтәлеклелек һ.б.) табылуын ассызыклый.

Телнең сүзлек составында бу берәмлекләрнең урынын билгеләгәндә, галимә соматизмнарның төрле өлкәләргә (кием-салым, бизәнү әйберләре, үлчәү берәмлекләре, җир-су атамалары, флора һәм фауна, ономастика һ.б.) караган лексик-семантик төркемнәргә үтеп керүен күрсәтеп кенә калмый, бәлки аның юлларын (семантик күчешләр, номинация алымы, метафора, чагыштырулар һ.б.) да ача. Мәсәлән, *баш* сүзенең мәгънә үсешендә әлеге алымнарның барысы да күзәтелә, моны хезмәттә китерелгән таблицалар да ачык чагылдыра. Соматизмнардагы күпмәгънәлелек аларның аеруча борынгы катлам икәнен күрсәтеп торуы Д.Б.Рамазанова хезмәтендә бай фактик материал нигезендә дәлилләнгән. Бу яктан әлеге китап телнең иҗтимагый күренеш икәнен раслый, үстерә бара. Иҗтимагый үсеш-үзгәреш барышында җәмгыятьтә туган һәрбер яңалык, яңа артефактларны атау ихтыяҗы кеше өчен иң таныш һәм иң якын әгъзалар белән чагыштырып белдерелә: *1) күз → буш тишек, чокыр → икмәктәге күзләр → шәл бәйләгәндәге тишекләр → ачкыч тишеге → тегермән ташы тишеге һ.б.; 2) күз – кайнап чыга торган чишмәнең тулып торган чокыры→күлләвекнең уртасы → җылу → мөлдерәмә тулы чиләк һ.б. → боткада май чокыры* һ.б. Автор хаклы рәвештә күпмәгънәлелекнең сәбәбе, нигезе борынгылыкта, дип саный.

Монографиянең өченче бүлегендә кешенең холкын, эчке дөньясын, психик халәтен сурәтли торган сүзләр анализлана. Бу төркем сүзләр мәгънә эчтәлеге, шулай ук килеп чыгышы, сүзьясалыш үзенчәлекләре белән дә телдәге башка берәмлекләрдән аерылып тора.

Кешене бәяли торган сүзләрнең мәгънәләре конкретлык җитмәү белән характерлана. Мәсәлән, *чибәр* сүзе *матур* сүзенең синонимы буларак билгеле. Әмма ул сөйләшләрдә «яхшы», «әйбәт», «шәп», «тәртипле», «сак, ипләп (йөрү)» мәгънәләрендә дә күзәтелә. Бу өлкәгә караган кайбер сүзләрнең мәгънәләре бөтенләй үзгәреп китәргә мөмкин: *кыланчыклану → мактану, кылану – эреләнү* һ.б.

Татар сөйләшләрендә *җукы, тәкәббер, тәпәренү* кебек сүзләргә бай семантик спектр хас. Автор аларның тамырдагы күпсанлы морфологик вариантларын туплап, аңлатып бирә, татар теленең эчке, семантик һәм грамматик мөмкинлекләрен ачыклый.

Кешенең холкын, эчке рухиятен сыйфатлый торган сүзләр килеп чыгышлары һәм формалары белән дә үзенчәлекле. Бу төркем берәмлекләрнең зур өлеше ясалма сүзләр һәм алар телдәге продуктив кушымчалар ярдәмендә ясалалар: *зиһенле, ямьсез, акыллы, чәүчәләк, күркәм; баштак, портак; кукыр, ацуланкыр, сизгер; борнай, сатай* һ.б.

Кешене характерлый торган сүзләрнең кайберләре тарихта билгеле булган шәхесләрнең исемнәренә, социаль терминнарга кайтып калган очраклар да бар: *каун, йот, әзмәвер* һ.б.

Татар халык медицинасы лексикасы һәм кайбер авыру атамаларын барлауны һәм тикшерүне күздә тоткан дүртенче бүлек моңа кадәр лингвоструктур һәм башка аспектларда махсус тикшеренү объекты булмаган материалны туплап бирә. Авыру исемнәренең, авыруларны дәвалауда кулланыла торган һәртөрле алымнарның атамалары халыкның рухи дөньясы, ышанулары, эстетик карашлары белән тыгыз бәйләнгән, алар халыкның фәлсәфи, гамәли фикер йөртүен күрсәтә. Болар барысы да халыкның телдә сурәтләнгән дөнья картинасын тудыруга зур өлеш кертә. Бу бүлек материаллары татар тел белемендә соңгы елларда актив үсеп килә торган лингвокультурологик эзләнүләр өчен бай чыганак булуы белән дә кыйммәтле.

Бишенче бүлек «Кеше белән бәйле лексикада ясагыч кушымчалар» дип атала һәм хезмәттә мисал итеп китерелгән берәмлекләрдәге ясагыч кушымчаларны барлауга багышлана. Бу бүлектәге материал кеше белән бәйле лексиканың бик борынгы катлам булуын тагын бер кат исбатлый: берәмлекләр составындагы күпчелек ясагыч кушымчалар кайчандыр актив булсалар да (моны аларның шактый күп сүзләрдә очраулары дәлилли), хәзерге телдә аларның кайберләрен морфема буларак аеру да кыенлык тудыра. Мисал өчен, *-әби: чәтнәби, чәтәби, этәмби; -мыр/-мер: бетмер, кысмыр, пытымыр, чыкмыр* һ.б. Шунысына да игътибар итәргә кирәк: бу кушымчалар әдәби телдә санаулы берәмлекләрдә генә күзәтелә, ә сөйләшләрдә аларны сүзьясагыч кушымча буларак аеру максатка ярашлы булуын исбатлый торган бай материал сакланган.

Д.Б.Рамазанова хезмәтендәге зур яңалыкларның берсе – мисал итеп китерелгән берәмлекләрне семантик аспектта да өйрәнү. Гомумән, хәзерге тел белемендә семасиология юнәлеше активлашып бара. Әлеге монография дә заман таләпләренә җавап бирә торган, тел белемендәге актуаль проблемаларны күз уңында тоткан фәнни хезмәт буларак бәяләүгә лаек. Анда лексемалардагы мәгънә күчешләрен күзәтүгә зур урын бирелә, тамыр сүзнең мәгънә спектрын барлауга, шул спектрдагы мәгънәләрнең үсү юлларын ачыклауга игътибар ителә.

Соматизмнарга хас мәгънә күчешләре арасында әгъза атамасы шул әгъзаны каплый торган кием, җайланма атамасы булып китү күренеше бик актив. Китапта *әгъза – кием* мәгънә күчеше системалы яктыртылып барыла. Бу закончалык тарих дәвамында кулланыштан төшеп калган атамаларны реконструкцияләргә ярдәм итә.

Нәтиҗә ясап, шуны билгеләп үтәргә кирәк: әлеге хезмәт татар әдәби телендә һәм аның күпсанлы сөйләшләрендә кеше белән бәйле сүзләр төркеменең гаять бай, генетик яктан катлаулы, структур яктан күпкырлы булуын дәлилли. Анда бу сүзләрнең татар теле лексикасында төп урынны алып торуы һәм телнең лексик байлыгы формалашуда зур роль уйнавы күләмле фактик материал нигезендә исбатлана. Д.Б.Рамазанованың «Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика» монографиясе тел белемендәге актуаль проблемаларны өйрәнүгә, хәл итүгә лаеклы өлеш кертә. Анда сайлап алынган темага караган материал югары дәрәҗәдә тикшерелгән һәм анализланган. Бу

хезмәт татар теле лексикасының башка тематик төркемнәре буенча да яңадан-яңа эзләнүләргә, ачышларга этәрер дип уйлыйбыз. Татар халкының тормышында зур урын алып торган, төп төшенчәләрне атаган лексик байлыкны өйрәнү халыкның үткәнен тулырак күзалларга, мәдәнияте, яшәеше үзгәрүе нәтиҗәсендә телдә барган үсеш-үзгәрешне күзәтергә мөмкинлек бирәчәк.

# РЕЦЕНЗИЯ НА МОНОГРАФИЮ Д.Б.РАМАЗАНОВОЙ «ТАТАР ТЕЛЕНДӘ КЕШЕГӘ БӘЙЛӘНЕШЛЕ ЛЕКСИКА»

**Раушания Сагдатзяновна Нурмухаметова**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420021, г. Казань, ул. Татарстан, д.2,
rsagadat@yandex.ru

В книге известного диалектолога, доктора филологических наук, профессора Д.Б.Рамазановой лексика, связанная с человеком, исследуется в диахроническом и синхроническом аспектах и в сопоставлении с другими языками; описываются семантические переходы в некоторых названиях; определяются генетические пласты данной лексики; приводятся интересные примеры общей с финно-угорскими языками лексики. То, что данная группа слов была сформирована в древние времена, аргументируется богатым фактическим материалом.

**Ключевые слова:** лексика, лексико-семантическая группа, соматизмы, термины.